Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №LV-4**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 4 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 07.07.2022 елның XXII-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләр тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт хакын тәртипкә китерү һәм камилләштерү максатларында муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт хакы түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 № 182 карарына үзгәрешләр кертү хакында»25.09.2024 ел, № 829 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 07.07.2022 елның XXII-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче Кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә

органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторларына хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 группа |
| Муниципаль район Башлыгы | 37036 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 33333 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе | 33333 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 29937 |
| Муниципаль районның контроль-хисап органы аудиторы | 25461 |

1.2. 3нче Кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| N п/п | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|
| | | 8 группа |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 36374 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 33017 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 32737 |
| 4. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 32597 |
| 5. | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 29939 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 26581 |
| 7. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире), башка структур бүлекчәсе (аппараты) җитәкчесе | 25462 |
| 8. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы урынбасары | 25182 |
| 9. | Башкарма комитетның мөстәкыйль бүлеге башлыгы (мөдире) урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 22245 |
| 10. | Муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе | 22245 |
| 11. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек | 22245 |

| | | |
|---|---|---|
| | башлыгы | |
| 12. | Сектор мөдире | 20566 |
| 13. | Баш белгеч | 19726 |
| 14. | Әйдәп баручы белгеч | 18327 |

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үзләренең хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерүен билгеләргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы Р.Р. Ислямов